ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

**«20» «февраль 2021 ел** **№ 213**

**«Җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалануны тәэмин итүдә гражданнарга бердәм электрон социаль юл йөрү билетлары (ташламалы транспорт картасы) буенча хезмәт күрсәтүләр белән бәйле алынмаган керемнәрне каплау максаты белән оешмаларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 10 мартындагы 153 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Кадрлар үзгәрү белән бәйле рәвештә Арча муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалануны тәэмин итүдә гражданнарга бердәм электрон социаль юл йөрү билетлары (ташламалы транспорт картасы) буенча хезмәт күрсәтүләр белән бәйле алынмаган керемнәрне каплау максаты белән оешмаларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 10 мартындагы 153 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
2. Субсидия алу хокукына дәгъва кылучы юридик затларны, шәхси эшкуарларны, физик затларны сайлап алуны гамәлгә ашыручы комиссия составын (3 нче кушымта) әлеге карарга кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.
4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Башкарма комитет җитәкчесе Р.М.Гатиятов

Арча муниципаль районы
Башкарма комитетының
20.02.2023 ел, №213
карарына кушымта

Субсидия алу хокукына дәгъва кылучы юридик затларны, шәхси эшкуарларны, физик затларны сайлап алуны гамәлгә ашыручы комиссия составы

| | |
|---|---|
| Галимуллин И.Ә. | Арча муниципаль районы<br>Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары |
| Галимова С. П. | «Арча муниципаль районының финанс-бюджет палатасы»<br>МКУ җитәкчесе |
| Галиуллина Р.Р. | Арча муниципаль районы Башкарма комитетының<br>бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлеге башлыгы |
| Галимуллина Г.Х. | Арча муниципаль районы Башкарма комитетының<br>икътисад һәм финанс бүлеге башлыгы |
| Хидиятуллин М.И. | Арча муниципаль районы Башкарма комитетының<br>инфраструктура үсеше бүлегенең баш белгече |